# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составына керүче Красная Горка авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 13 «16» октябрь, 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче матдәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 матдәсе, Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылында 2023 елның «16» октябрендә, узарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенынын түбәндәге беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган гражданнарга, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2025 елда 400 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карау (Красная Горка авылында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау, Красная Горка авылында ком һәм вак таш түшәлгән юлны ремонтлау, Красная Горка авылында юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру, юлларның асфальтланган урыннарына юл билгеләре сызу, Красная Горка авылы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;

-тротуарлар төзү, ремонтлау (Красная Горка авылында, Ямашев ур.);

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен күперләрне һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Красная Горка авылында елга аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлау);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Красная Горка авылында балалар һәм спорт мәйданчыкларын ремонтлау);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау (Красная Горка авылында

урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру):

« ӘЙЕ » « ЮК »

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган, җыенда катнашучылар исемлегенә 895 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 638 кеше, 71,3% тәшкил итә:
Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 638 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләрен - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: « Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Красная Горка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган гражданнарга, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2025 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карау (Красная Горка авылында вак таш җәелгән юлларны ремонтлау, Красная Горка авылында ком һәм вак таш түшәлгән юлны ремонтлау, Красная Горка авылында юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру, юлларның асфальтланган урыннарына юл билгеләре сызу, Красная Горка авылы урамнары юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү;

-тротуарлар төзү, ремонтлау (Красная Горка авылында, Ямашев ур.);

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен күперләрне һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (Красная Горка авылында елга аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлау);

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Красная Горка авылында балалар һәм спорт мәйданчыкларын ремонтлау);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау (Красная Горка авылында

урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

3.Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гиззатуллина